КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 29 декабрь г.Казань № 1264

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга «Ачык Татарстан» Татарстан Республикасында мәгълүмат һәм коммуникация технологияләрен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 17 декабрь, 1000 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга «Ачык Татарстан» Татарстан Республикасында мәгълүмат һәм коммуникация технологияләрен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 17 декабрь, 1000 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 8 июль, 470 нче; 2014 ел, 30 декабрь, 1062 нче; 2015 ел, 17 август, 604 нче; 2016 ел, 19 гыйнвар, 24 нче һәм 2016 ел, 23 декабрь, 979 нчы һәм 2017 ел, 14 ноябрь, 871 нче; 2018 ел, 9 июнь, 445 нче; 2018 ел, 28 август, 720 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә һәм 1 пунктта «2014 – 2020» саннарын «2014 – 2021» саннарына алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган «2014 – 2020 елларга «Ачык Татарстан» Татарстан Республикасында мәгълүмат һәм коммуникация технологияләрен үстерү» дәүләт программасында (алга таба – Программа)

исемендә 2014 – 2020» саннарын «2014 – 2021» саннарына алмаштырырга;

Программа паспортын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Программа паспорты

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | «2014 – 2021 елларга «Ачык Татарстан» Татарстан Республикасында мәгълүмат һәм коммуникация технологияләрен үстерү» дәүләт программасы (алга таба – Программа) |
| Программаның дәүләт заказчылары | Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм элемтә министрлыгы;<br>Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы |
| Программаның дәүләт заказчысы – яраштыручысы | Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм элемтә министрлыгы |
| Программаны төп эшләүчеләр | Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм элемтә министрлыгы;<br>Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы;<br>«Югары технологияләр өлкәсендәге «ИТ-парк» технопаркы дәүләт автоном учреждениесе;<br>«Татарстан Республикасы мәгълүмат технологияләре үзәге» дәүләт унитар предприятиесе |
| Программаның максатлары | Эшчәнлекнең барлык өлкәләрендә инфокоммуникацион һәм инновацион технологияләрне гамәлгә кертү һәм киң куллану, Татарстан Республикасының бердәм мәгълүмати җәмгыятен булдыру һәм Татарстан Республикасының глобаль мәгълүмати җәмгыятькә интеграцияләү |
| Программаның бурычлары | 1. Гражданнарның һәм оешмаларның мәгълүмат-коммуникация технологияләре нигезендә дәүләт, муниципаль һәм социаль әһәмиятле хезмәт күрсәтүләрдән файдалана алуын оештыру.<br>2. Мәгълүмати-телекоммуникация технологияләрен үстерү һәм куллану нигезендә белем бирү, медицина хезмәте күрсәтү, халыкны социаль яклау сыйфатын күтәрү.<br>3. Республикада дәүләт идарәсе һәм дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының һәм граждан җәмгыятенең үзара хезмәттәшлеге нәтиҗәлелеген арттыру.<br>4. Республиканың дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарында мәгълүмат саклауны оештыру.<br>5. Заманча мәгълүмат һәм телекоммуникация инфраструктурасын формалаштыру, аның нигезендә |

| | |
|---|---|
| | сыйфатлы хезмәт күрсәтү.<br>6. Дәүләт һәм муниципаль идарә ихтыяҗлары өчен элемтә һәм телекоммуникацияләр системаларын үстерү.<br>7. Татарстан Республикасы территориясендә гражданлык җәмгыятен формалаштыруда массакүләм мәгълүмат чараларының ролен арттыру, республика халкының гомумкешелек кыйммәтләрен формалаштыру, республикада яшәүче халыкларның милли мәдәниятен саклау һәм үстерү.<br>8. Мәгълүмати технологияләр өлкәсе үсешен стимуллаштыру |
| Программаны тормышка ашыру вакытлары һәм этаплары | 2014 – 2021 еллар |
| Ярдәмче программалар исемлеге | 1. 2014 – 2021 елларга Мәгълүмати Татарстан.<br>2. 2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасы территориясендә мәгълүмат-телекоммуникация инфраструктурасын үстерү.<br>3. 2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасының мәгълүмати киңлек инфраструктурасын үстерү һәм камилләштерү.<br>4. 2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасында мәгълүмати технологияләр өлкәсендәге икътисадый мохитне һәм кеше капиталын үстерүгә дәүләт ярдәме күрсәтү |
| Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләмнәре | Алдан хисаплау буенча, Программаны финанслауның гомуми күләме 22 851 368,21 мең сум тәшкил итә, шулардан:<br>билгеләнгән тәртиптә җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы – 95 786,0 мең сум;<br>Татарстан Республикасы бюджеты акчасы – 22 755 582,21 мең сум.<br>Программаны еллар буенча финанслауның гомуми күләме:<br>2014 ел – 2 654 730,72 мең сум, шулардан федераль бюджеттан җәлеп итәргә планлаштырыла торган акча исәбеннән – 30 000,0 мең сум, Татарстан Республикасы бюджеты акчасы – 2 624 730,72 мең сум;<br>2015 ел – 2 534 592,01 мең сум, шулардан федераль бюджеттан җәлеп итәргә планлаштырыла торган акча исәбеннән – 30 000,0 мең сум, Татарстан Республикасы бюджеты акчасы – 2 504 592,01 мең сум; |

| | |
|---|---|
| | 2016 ел – 2 969 505,59 мең сум, шулардан Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 2 969 505,59 мең сум;<br>2017 ел – 3 136 360,87 мең сум, шулардан Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 3 136 360,87 мең сум;<br>2018 ел – 3 856 400,19 мең сум, шулардан Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 3 856 400,19 мең сум;<br>2019 ел – 2 580 460,0 мең сум, шулардан федераль бюджеттан җәлеп итәргә планлаштырыла торган акча исәбеннән – 35 786,0 мең сум, Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 2 544 674,0 мең сум;<br>2020 ел – 2 547 654,7 мең сум, шулардан Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 2 547 654,7 мең сум;<br>2021 ел – 2 571 664,13 мең сум, шулардан Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 2 571 664,13 мең сум.<br>Түбәндәгеләр буенча финанслауның гомуми күләме:<br>«2014 – 2021 елларга мәгълүмати Татарстан» ярдәмче программасы – 7 003 179,75 мең сум;<br>«2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасы территориясендә мәгълүмат-телекоммуникация инфраструктурасын үстерү» ярдәмче программасы – 5 154 454,46 мең сум;<br>«2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасының мәгълүмати киңлек инфраструктурасын үстерү һәм камилләштерү» ярдәмче программасы – 9 906 569,81 мең сум;<br>«2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасында мәгълүмати технологияләр өлкәсендәге икътисадый мохитне һәм кеше капиталын үстерүгә дәүләт ярдәме күрсәтү» ярдәмче программасы – 787 164,19 мең сум.<br>Программаны финанслау күләме фараз характеренда була һәм чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетын формалаштырганда ел саен билгеләнгән тәртиптә тәгаенләнергә тиеш |
| Еллар буенча бүлеп, Программа максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан | Программаны тормышка ашырудан көтелә торган нәтиҗәләр түбәндәгеләр:<br>дәүләт идарәсенең һәм җирле үзидарәнең, гражданлык җәмгыяте һәм бизнес белән дәүләт хакимияте органнары арасындагы үзара хезмәттәшлекнең нәтиҗәлелеген, дәүләт |

| | |
|---|---|
| көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм Пр-грамманың бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | хезмәтләре күрсәтүнең сыйфатын һәм оперативлыгын арттыру;<br>Татарстан Республикасы территориясендә заманча мәгълүмат һәм телекоммуникация инфраструктурасын төзү, аның нигезендә сыйфатлы хезмәтләр күрсәтү һәм халыкның мәгълүматтан һәм технологияләрдән файдалана алу дәрәҗәсе югары булуны тәэмин итү;<br>мәгълүмат һәм телекоммуникация технологияләреннән файдалану нигезендә белем бирү, медицина хезмәте күрсәтү, халыкны социаль яклау сыйфатын күтәрү, мәдәни агарту системасын үстерү;<br>мәгълүмати һәм телекоммуникацион технологияләрне файдалану нигезендә республиканың икътисадын үстерү;<br>гамәлдәге норматив документлар нигезендә дәүләт хакимияте органнарының мәгълүмат ресурсларын саклауны тәэмин итү.<br>Программа чараларын тормышка ашыру нәтиҗәсендә 2021 елда түбәндәге күрсәткечләргә ирешү планлаштырыла:<br>идентификацияләү һәм аутентификацияләүнең бердәм системасында теркәлгән Татарстан Республикасы гражданнары өчен 14 яшьтән өлкәнрәк булган гражданнарның гомуми санынннан – 78 процент;<br>«Инвалидларның мәгълүмат базасы» мәгълүмат системасында теркәлгән мөмкинлекләре чикләнгән кешеләрне тернәкләндерү программалары өлеше – 95 процент;<br>пациентларның гомуми саныннан электрон медицина карталары алып барыла торган пациентлар өлеше – 100 процент;<br>Татарстан Республикасының дистанцион укыту формаларына һәм электрон дәреслекләргә керү мөмкинлеге булган белем бирү оешмалары өлеше-99 процент;<br>күрсәтелгән дәүләт, муниципаль һәм социаль әһәмияткә ия хезмәтләр санының электрон рәвештә узган елның шул ук чорында күрсәтелә торган хезмәтләр санына карата – 110 процент;<br>дәүләт ресурсларын вакытлыча блокировкалауга китергән дәүләт мәгълүмат ресурсларында саклана торган һәм эшкәртелә торган мәгълүматтан хокуксыз файдалану фактларының саны – 0 берәмлек;<br>халыкара мәгълүмат киңлегенә интеграцияләнү дәрәҗәсе (санлы тапшырулар, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән киң полосалы файдалану |

| | |
|---|---|
| | мөмкинлеге) – 88 процент;<br>Татарстан Республикасы Телекоммуникацияләренең дәүләт интеграцияләнгән системасы ресурсларыннан файдалану мөмкинлеге алган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнары өчен «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәренә оештырылган тоташтырулар өлеше-100 процент;<br>республика халкының гомумкешелек кыйммәтләрен формалаштыруга, республикада яшәүче халыкларның милли мәдәниятен саклауга һәм үстерүгә багышланган Татарстан Республикасы массакүләм мәгълүмат чаралары материаллары саны динамикасы-5 процент;<br>югары җитештерүчәнлекле эш урыннары үсеше темпы - 112 процент.<br>Еллар буенча бүлеп, Программа максатларына һәм бурычларына ирешү күрсәткечләре (индикаторлары) 1 нче таблицада китерелә.<br>Чаралар буенча нәтиҗәләрне бәяләү күрсәткечләре (индикаторлары) Программага 1 нче кушымтада китерелә»; |

II һәм III бүлекләрне түбәндәге редакция бәян итәргә:

«II. Төп максатлар, бурычлар һәм максатларыга ирешү һәм бурычларны хәл итү күрсәткечләрк (индикаторлары), Программаның көтелгән төп ахыргы нәтиҗәләре тасвирламасы, Программаны гамәлгә ашыру вакытытдары һәм этаплары

Программаның төп максаты – эшчәнлекнең барлык өлкәләрендә инфокоммуникацион һәм инновацион технологияләрне кертү һәм киң куллану, Татарстан Республикасының бердәм мәгълүмати җәмгыятен булдыру һәм Татарстан Республикасының глобаль мәгълүмати җәмгыятькә интеграцияләү.

Программа чаралары Программа бурычларын чишүне тәэмин итүче 4 ярдәмче программа кысаларында башкарыла:

«2014 – 2021 елларга Мәгълүмати Татарстан» ярдәмче программасы;

«2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасы территориясендә мәгълүмат-телекоммуникация инфраструктурасын үстерү» ярдәмче программасы;

«2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасының мәгълүмати киңлек инфраструктурасын үстерү һәм камилләштерү» ярдәмче программасы;

«2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасында мәгълүмати технологияләр өлкәсендәге икътисадый мохитне һәм кеше капиталын үстерүгә дәүләт ярдәме күрсәтү» ярдәмче программасы.

«2014-2021 елларга мәгълүмати Татарстан» ярдәмче программасы чаралары түбәндәге бурычларны хәл итүне тәэмин итә:

гражданнарның һәм оешмаларның мәгълүмат-коммуникация технологияләре

нигезендә дәүләт, муниципаль һәм социаль әһәмиятле хезмәт күрсәтүләрдән файдалана алуын оештыру;

мәгълүмати-телекоммуникация технологияләрен үстерү һәм куллану нигезендә белем бирү, медицина хезмәте күрсәтү, халыкны социаль яклау сыйфатын күтәрү;

республикада дәүләт идарәсе һәм дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының һәм граждан җәмгыятенең үзара хезмәттәшлеге нәтиҗәлелеген арттыру;

республиканың дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарында мәгълүмат саклауны оештыру.

Әлеге ярдәмче программа икътисад һәм җәмгыять үсешенең актуаль ихтыяҗларын чагылдыра һәм теге яки бу эшчәнлек өлкәсендә хәл ителә торган бурычлар нигезендә оператив төзәтмәләр кертә ала.

Ярдәмче программаны үтәү хакимият органнары эшчәнлеген оештыруның яңа формасына күчүне, оешмалар һәм гражданнар тарафыннан дәүләт, муниципаль һәм социаль әһәмиятле хезмәтләр күрсәтүнең тизлеген һәм уңайлылыгын, шулай ук хакимият органнары эшчәнлегенең ачыклыгын арттыруны тәэмин итәчәк.

«2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасы территориясендә мәгълүмат-телекоммуникация инфраструктурасын үстерү» ярдәмче программасы чаралары түбәндәге бурычларны хәл итүне тәэмин итәләр:

заманча мәгълүмат һәм телекоммуникация инфраструктурасын формалаштыру, аның нигезендә сыйфатлы хезмәт күрсәтү;

дәүләт һәм муниципаль идарә ихтыяҗлары өчен элемтә һәм телекоммуникацияләр системаларын үстерү.

«2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасының мәгълүмати киңлек инфраструктурасын үстерү һәм камилләштерү» ярдәмче программасы чаралары массакүләм мәгълүмат чаралары өлкәсендә гамәлгә ашырыла һәм Татарстан Республикасы территориясендә граждан җәмгыятен формалаштыруда массакүләм мәгълүмат чараларының ролен арттыру, республика халкының гомумкешелек кыйммәтләрен формалаштыру, республикада яшәүче халыкларның милли мәдәниятен саклап калу һәм үстерү мәсьәләләрен хәл итүне тәэмин итә.

«2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасында мәгълүмати технологияләр өлкәсендәге икътисадый мохитне һәм кеше капиталын үстерүгә дәүләт ярдәме күрсәтү» ярдәмче программасы чаралары мәгълүмати-телекоммуникация технологияләре өлкәсендә дәүләт ярдәме күрсәтү һәм квалификацияле кадрлар әзерләү юлы белән мәгълүмати технологияләр өлкәсен үстерү бурычларын хәл итүне тәэмин итәләр.

Программаның төп чаралары һәм аларны тормышка ашыруны бәяләү индикаторлары исемлеге Программага теркәлгән 1 нче кушымтада китерелә.

«1 нче таблица

Еллар буенча Программа максатларына һәм бурычларына ирешү күрсәткечләре (индикаторлары)

| Максат | Бурыч | Индикатор | 2013 ел | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
| Эшчәнлекнең барлык өлкәләрендә инфокоммуникацион һәм инновацион технологияләрне гамәлгә кертү һәм киң файдалану, Татарстан Республикасының бердәй мәгълүмати җәмгыятен булдыру һәм Татарстан Республикасын глобаль мәгълүмати җәмгыяткә интеграцияләү | 1. Гражданнар һәм оешмаларның мәгълүмат-коммуникация технологияләре нигезендә дәүләт, муниципаль һәм социаль әһәмияттәге хезмәт күрсәтүләрдән файдалану мөмкинлеген оештыру | Татарстан Республикасының 14 яшьтән өлкән гражданнарының гомуми санында Идентификацияләү һәм аутентификацияләүнең бердәм системасында теркәлгән Татарстан Республикасы гражданнары өлеше, процент | 0 | 3 | 8 | 28 | 63 | 72 | 74 | 76 | 78 |
| | 2. Мәгълүмат-коммуникация технологияләрен үстерү һәм куллану нигезендә мәгарифнең, медицина хезмәте күрсәтүнең, халыкны социаль яклауның сыйфатын күтәрү | «Инвалидларның мәгълүмат базасы» мәгълүмат системасында теркәлгән мөмкинлекләре чикләнгән кешеләрне тернәкләндерү программалары өлеше, процент | 0 | 10 | 25 | 40 | 70 | 90 | 93 | 95 | 95 |
| | | пациентларның гомуми санында электрон медицина карталары алып барыла торган пациентлар өлеше, процент | 40 | 45 | 50 | 80 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | дистанцион укыту формаларыннан һәм электрон дәреслекләрдән файдалану мөмкинлеге булган Татарстан Республикасы мәгариф оешмалары өлеше, процент | 86 | 87 | 87 | 97 | 97 | 98 | 99 | 99 | 100 |
| | 3. Республикада дәүләт идарәсенең һәм дәүләт һәм муниципаль хакимият органнарының һәм гражданнар җәмгыятенең нәтиҗәлелеген күтәрү | электрон рәвештә күрсәтелгән дәүләт, муниципаль һәм социаль әһәмияттәге хезмәтләрнең узган елның шул чорындагы хезмәтләр санына карата мөнәсәбәте, процент | 367 | 126 | 184 | 110 | 115 | 115 | 115 | 115 | 110 |
| | 4. Республиканың дәүләт һәм муниципаль хакимият органнарында мәгълүматны саклауны оештыру | Дәүләт мәгълүмат ресурсларында саклана һәм эшкәртелә торган мәгълүматтан хокуксыз файдалануның дәүләт ресурсларын вакытлыча блокировкалауга китергән фактлар саны, берәмлек | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 |
| | 5. Заманча информацион һәм телекоммуникацион инфраструктура формалаштыру, аның ниге- | халыкара мәгълүмат киңлегенә интеграцияләү дәрәҗәсе (санлы тапшыру, «Интернет» мәгълүмат- | 78 | 82 | 84 | 87 | 87 | 87 | 88 | 88 | 88 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | зендә сыйфатлы хезмәтләр күрсәтү | телекоммуникация челтәренә киң полосалы керү), процент | | | | | | | | | |
| | 6. Дәүләт һәм муниципаль идарә ихтыяҗлары өчен элемтә һәм телекоммуникация системаларын үстерү | Татарстан Республикасының дәүләт интеграцияләнгән телекоммуникацияләр системасына керү мөмкинлеге алган Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хакимият органнары өчен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренә оештырылган тоташтырулар өлеше, процент | 87,1 | 89,9 | 92,2 | 94,5 | 96,6 | 97,8 | 98,3 | 100 | |
| | 7. Татарстан Республикасы территориясендә гражданнар җәмгыятен формалаштыруда массакүләм мәгълүмат чаралары роле арту, республикада яшәүчеләрнең гомумкешелек кыйммәтләрен формалаштыру, республикада яшәүче халыкларның милли мәдәниятләрен саклау һәм үстерү | Татарстан Республикасы массакүләм мәгълүмат чараларының республикада яшәүчеләрнең гомумкешелек кыйммәтләрен формалаштыру, республикада яшәүче халыкларның милли мәдәниятләрен саклау һәм үстерүгә багышланган материаллары саны динамикасы, процент | 0 | 0 | 0 | 5 | 5 | 5 | 5 | 5 | 5 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | 8. Мәгълүмат технологияләре тармагын үстерүне стимуллаштыру | югары житештерүчәнлекле эш урыннары санын үстерү темпы, процент | - | - | - | - | 108 | 110 | 112 | 112 | 112 |

«III. Программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

Алдан хисаплау буенча, Программаны финанслауның гомуми күләме 22 851 368,21 мең сум тәшкил итә, шулардан:
җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы – 95 786,0 мең сум;
Татарстан Республикасы бюджеты акчасы – 22 755 582,21 мең сум.

2 нче таблица

Ярдәмче программалар һәм еллар буенча Программаны финанслау күләме

(мең сум)

| Ярдәмче программаның исеме | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел | Барлык акча |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
| «2014 – 2020 елларга Мәгълүмати Татарстан», шулардан: | 644 534,59 | 669 628,19 | 1 024 496,24 | 1 045 080,47 | 1 373 962,36 | 772 068,3 | 736 282,3 | 737 127,3 | 7 003 179,75 |
| җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы | 30 000,0 | 30 000,0 | - | - | - | 35 786,0 | - | | 95 786,0 |
| Татарстан Республикасы бюджеты акчасы | 614 534,59 | 639 628,19 | 1 024 496,24 | 1 045 080,47 | 1 373 962,36 | 736 282,3 | 736 282,3 | 737 127,3 | 6 907 393,75 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы территориясендә мәгълүмат-телекоммуникация инфраструктурасын үстерү», шулардан: | 685 173,9 | 569 956,08 | 616 400,75 | 722 519,7 | 818 650,43 | 576 511,2 | 576 511,2 | 588 731,2 | 5 154 454,46 |
| Татарстан Республикасы бюджеты акчасы | 685 173,9 | 569 956,08 | 616 400,75 | 722 519,7 | 818 650,43 | 576 511,2 | 576 511,2 | 588 731,2 | 5 154 454,46 |
| «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының мәгълүмат киңлеге инфраструктурасын үстерү һәм камилләштерү», шулардан: | 1 197 028,0 | 1 192 716,6 | 1 219 441,13 | 1 250 259,18 | 1 558 911,9 | 1 160 727,8 | 1 162 320,1 | 1 165 165,1 | 9 906 569,81 |
| Татарстан Республикасы бюджеты акчасы | 1 197 028,0 | 1 192 716,6 | 1 219 441,13 | 1 250 259,18 | 1 558 911,9 | 1 160 727,8 | 1 162 320,1 | 1 165 165,1 | 9 906 569,81 |
| «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында мәгълүмат технологияләре өлкәсендә икътисадый мохитне һәм кеше капиталын үстерүгә дәүләт ярдәме», шулардан: | 127 994,23 | 102 291,14 | 109 167,47 | 118 501,52 | 104 875,5 | 71 152,7 | 72 541,1 | 80 640,53 | 787 164,19 |
| Татарстан Республикасы бюджеты акчасы | 127 994,23 | 102 291,14 | 109 167,47 | 118 501,52 | 104 875,5 | 71 152,7 | 72 541,1 | 80 640,53 | 787 164,19 |
| БАРЛЫГЫ, шулардан: | 2 654 730,72 | 2 534 592,01 | 2 969 505,59 | 3 136 360,87 | 3 856 400,19 | 2 580 460,0 | 2 547 654,7 | 2 571 664,13 | 22 851 368,21 |
| планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы | 30 000,0 | 30 000,0 | - | - | - | 35 786,0 | - | - | 95 786,0 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Татарстан Республикасы бюджеты акчасы | 2 624 730,72 | 2 504 592,01 | 2 969 505,59 | 3 136 360,87 | 3 856 400,19 | 2 544 674,0 | 2 547 654,7 | 2 571 664,13 | 22 755 582,21 |

Программаны финанслау күләме фараз характеренда була һәм тиешле елга һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетын формалаштырганда ел саен билгеләнгән тәртиптә тәгаенләнергә тиеш.

Программаны озак вакытлы чорга финанслау күләмнәрен исәпләү 2030 елга кадәрге чорга Россия Федерациясенең озак вакытлы социаль-икътисадый үсеш фаразы инфляциясе индекслары нигезендә башкарылды.

3 нче таблица

Бюджет акчасы белән баш эш итүчеләр һәм елл ар буенча Программаны финанслау күләме

(мең сум)

| Бюджет акчасы белән баш эш итүче | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел | Барлык акча |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы, шулардан: | 1 457 702,72 | 1 341 875,41 | 1 750 064,46 | 1 886 101,69 | 2 297 488,29 | 1 419 732,2 | 1 385 334,6 | 1 406 499,03 | 12 944 798,4 |
| җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы | 30 000,0 | 30 000,0 | - | - | - | 35 786,0 | - | - | 95 786,0 |
| Татарстан Республикасы бюджеты акчасы | 1 427 702,72 | 1 311 875,41 | 1 750 064,46 | 1 886 101,69 | 2 297 488,29 | 1 383 946,2 | 1 385 334,6 | 1 406 499,03 | 12 849 012,4 |
| Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы, шулардан: | 1 197 028,0 | 1 192 716,6 | 1 219 441,13 | 1 250 259,18 | 1 558 911,9 | 1 160 727,8 | 1 162 320,1 | 1 165 165,1 | 9 906 569,81 |
| Татарстан Республикасы бюджеты акчасы | 1 197 028,0 | 1 192 716,6 | 1 219 441,13 | 1 247 161,8 | 1 558 911,9 | 1 160 727,8 | 1 162 320,1 | 1 165 165,1 | 9 906 569,81 |

Программа чараларын финанслау күләме программага 2 нче кушымтада китерелгән.»;
«2014 – 2020 елларга  Мәгълүмати Татарстан» ярдәмче программасында:
исемендә «2014 – 2020» саннарын  «2014 – 2021» саннарына алмаштырырга;
Ярдәмче программа паспортын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ярдәмче программа паспорты

| | |
|---|---|
| Ярдәмче программаның исеме | «2014 – 2021 елларга Мәгълүмати Татарстан» (алга таба – Ярдәмче программа) |
| Ярдәмче программаның дәүләт заказчысы | Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм элемтә министрлыгы |
| Ярдәмче программаның максатлары | 1. Дәүләт, муниципаль һәм социаль әһәмияткә ия хезмәт күрсәтү дәрәҗәсен, сыйфатын һәм һәркем файдалана алырлык булуын арттыру.<br>2. Башкарма хакимият органнарында мәгълүмат ачыклыгын арттыру һәм административ-идарә процессларын камилләштерү |
| Ярдәмче программаның бурычлары | 1. Дәүләт, муниципаль һәм социаль әһәмиятле хезмәтләрне электрон рәвештә алу, шулай ук «бер тәрәзә» режимында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре базасында автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып «бер тәрәзә» режимында хезмәт күрсәтү мөмкинлеген тәэмин итү.<br>2. Социаль өлкә тармакларында мәгълүмати-коммуникацион технологияләрне кертү.<br>3. Җәмгыять һәм дәүләт хакимияте органнарының аралашу процедураларын гадиләштерү өчен ИТ-технологияләр нигезендә сервисларны үстерү.<br>4. Республиканың бердәм геомәгълүмат киңлеген үстерү.<br>5. Татарстан Республикасының мәгълүмати иминлеген тәэмин итү |
| Ярдәмче программаны тормышка ашыру вакытлары һәм этаплары | 2014 – 2021 еллар |
| Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре | Алдан хисаплау буенча, Ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 7 003 179,75 мең сум тәшкил итә, шулардан:<br>билгеләнгән тәртиптә җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы – 95 786,0 мең сум;<br>Татарстан Республикасы бюджеты акчасы – 6 907 393,75 мең сум. |

| | |
|---|---|
| | Ярдәмче программаны еллар буенча финанслауның гомуми күләме:<br>2014 ел – 644 534,59 мең сум, шулардан федераль бюджеттан җәлеп итәргә планлаштырыла торган акча исәбеннән – 30 000,0 мең сум, Татарстан Республикасы бюджеты акчасы – 614 534,59 мең сум;<br>2015 ел – 669 628,19 мең сум, шулардан федераль бюджеттан җәлеп итәргә планлаштырыла торган акча исәбеннән – 30 000,0 мең сум, Татарстан Республикасы бюджеты акчасы – 639 628,19 мең сум;<br>2016 ел – Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән 1 024 496,24 мең сум;<br>2017 ел – Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән 1 045 080,47 мең сум;<br>2018 ел – Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән 1 373 962,36 мең сум;<br>2019 ел – 772 068,3 мең сум, шулардан җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы – 35 786,0 мең сум, Татарстан Республикасы бюджеты акчасы – 736 282,3 мең сум;<br>2020 ел – Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән 736 282,3 мең сум;<br>2021 ел – Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән 737 127,3 мең сум.<br>Ярдәмче программаны финанслау күләме фараз характерында була һәм чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетын формалаштырганда ел саен билгеләнгән тәртиптә тәгаенләнергә тиеш |
| Еллар буенча бүлеп, Ярдәмче программаны тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм Ярдәмче программаның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | Ярдәмче программаны тормышка ашыру барышында 2021 ел ахырына түбәндәге күрсәткечләргә ирешү планлаштырыла:<br>узган елның шул ук чорына карата күпфункцияле үзәкләр (КФҮ) базасында автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан (алга таба - АМС) файдаланып алынган дәүләт, муниципаль һәм социаль әһәмияттәге хезмәт күрстәүләр саны үсү темплары – 115 процент;<br>«Татарстан Республикасында Электрон мәгариф» дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланучылар саны – 1 005 мең кеше; |

| | |
|---|---|
| | «Татарстан Республикасының Электрон сәламәтлек саклавы» бердәм дәүләт мәгълүмат системасына тоташтырылган медицина оешмалары өлеше – 100 процент;<br>учреждениеләр эшен автоматлаштыручы мәгълүмати системаларына тоташтырылган мәдәният учреждениеләре өлеше-17 процент;<br>социаль яклау хезмәтләрен электрон рәвештә алучы гражданнарның өлеше-75 процент;<br>дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә ведомствоара хезмәттәшлек итүдә катнашучы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнары арасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең төбәк системасын кулланучы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары өлеше – 100 процент;<br>Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 9 февралендәге 232-р номерлы боерыгы нигезендә Татарстан Республикасы геопорталында урнаштырылган координатадан файдаланып, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары карамагында булган мәгълүматлар өлеше-100 процент;<br>дәүләт ресурсларын вакытлыча блокировкалауга китергән дәүләт мәгълүмат ресурсларында саклана торган һәм эшкәртелә торган мәгълүматтан хокуксыз файдалану фактларының саны – 0 берәмлек.<br>Еллар буенча бүлеп, Ярдәмче программаны тормышка ашыруны бәяләү күрсәткечләре (индикаторлары) 1 нче таблицада китерелә»; |

II бүлектә:

унынчы абзацта «2014 – 2020» саннарын «2014 – 2021» саннарына алмаштырырга;

1 нче таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1 нче таблица

Еллар буенча Программа максатларына һәм бурычларына ирешү күрсәткечләре (индикаторлары)

| Максат | Бурыч | Индикатор | 2013 ел | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
| 1. Дәүләт, муниципаль һәм социаль әһәмияткә ия хезмәт күрсәтүләрнең дәрәҗәсен, сыйфатын һәм һәркем файдалана алырлык булуын арттыру | 1.1. Дәүләт, муниципаль һәм социаль әһәмиятле хезмәтләрне электрон рәвештә алу, шулай ук КФҮ базасында АИС кулланып «бер тәрәзә» режимында хезмәт күрсәтү мөмкинлеген тәэмин итү | КФҮ базасында АИС кулланып алынган дәүләт, муниципаль һәм социаль әһәмиятле хезмәтләр санының үсеш темпы, узган елның шушы чорына карата, % | 0 | 0 | 406 | 333 | 115 | 115 | 115 | 115 | 115 |
| | 1.2. Социаль өлкә тармакларында мәгълүмати-коммуникацион технологияләр кертү | «Татарстан Республикасында электрон мәгариф» дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланучылар саны, мең кеше | 900 | 970 | 1 000 | 1 003 | 1 003 | 1 003 | 1 003 | 1 003 | 1 005 |
| | | «Татарстан Республикасы Электрон сәламәтлек саклау» бердәм дәүләт мәгълүмат системасына тоташтырылган медицина оешмалары өлеше, % | 0 | 40 | 60 | 80 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 |
| | | мәгълүмати системалары учреждениеләре эшен автоматлашты- | 6 | 7 | 9 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | ручыларга тоташкан мәдәният учреждениеләре өлеше, % | | | | | | | | | |
| | | социаль яклау хезмәтләрен электрон рәвештә алучы гражданнар өлеше, % | 0 | 0 | 33 | 63 | 65 | 65 | 65 | 70 | 75 |
| 2. Башкарма хакимият органнарында мәгълүмат ачыклыгын арттыру һәм административ-идарә процессларын камилләштерү | 2.1. Җәмгыять һәм дәүләт хакимияте органнарының аралашу процедураларын гадиләштерү өчен ИТ-технологияләр нигезендә сервисларны үстерү | дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә ведомствоара хезмәттәшлек итүдә катнашучы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары арасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең региональ системасын кулланучы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары өлеше, % | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | 2.2. Республиканың бердәм геомәгълүмат киңлеген үстерү | Татарстан Республикасы геопорталында урнаштырылган Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 9 февралендәге 232-р номерлы боерыгы нигезендә координатаны кулланып күрсәтелергә тиеш, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары карамагында булган мәгълүматлар өлеше, % | - | - | - | - | 23 | 50 | 75 | 100 | 100 |
| | 2.3. Татарстан Республикасының мәгълүмат иминлеген тәэмин итү | дәүләт ресурсларын вакытлыча блокировкалауга китергән дәүләт мәгълүмат ресурсларында саклана торган һәм эшкәртелә торган мәгълүматтан хокуксыз файдалану фактларының саны, берәмлек | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0»; |

III бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. Ярдәмче программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

Алдан хисаплау буенча, Ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 7 003 179,75 мең сум тәшкил итә, шулардан:

җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы – 95 786,0 мең сум;

Татарстан Республикасы бюджеты акчасы – 6 907 393,75 мең сум.

2 нче таблица

Еллар буенча Ярдәмче программаны финанслау күләме

(мең сум)

| Финанслау чыганагы | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел | Барлык акча |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Финанслауның гомуми күләме, шулардан: | 644 534,59 | 669 628,19 | 1 024 496,24 | 1 045 080,47 | 1 373 962,36 | 772 068,3 | 736 282,3 | 737 127,3 | 7 003 179,75 |
| җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы | 30 000,0 | 30 000,0 | - | - | - | 35 786,0 | - | - | 95 786,00 |
| Татарстан Республикасы бюджеты акчасы | 614 534,59 | 639 628,19 | 1 024 496,24 | 1 045 080,47 | 1 373 962,36 | 736 282,3 | 736 282,3 | 737 127,3 | 6 907 393,75 |

Программаны финанслау күләме фараз характеренда була һәм тиешле елга һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетын формалаштырганда ел саен билгеләнгән тәртиптә тәгаенләнергә тиеш.

Ярдәмче программаны озак вакытлы чорга финанслау күләмнәрен исәпләү 2030 елга кадәрге чорга Россия Федерациясенең озак вакытлы социаль-икътисадый үсеш фаразы инфляциясе индекслары нигезендә башкарылды.»;

«2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы территориясендә мәгълүмат-коммуникация инфраструктурасын үстерү» ярдәмче программасында:

исемендә «2014 – 2020» саннарын «2014 – 2021» саннарына алмаштырырга;

Ярдәмче программа паспортын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ярдәмче программа паспорты

| | |
|---|---|
| Ярдәмче программаның исеме | «2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасы территориясендә мәгълүмат-коммуникация инфраструктурасын үстерү» (алга таба – Ярдәмче программа) |
| Ярдәмче программаның дәүләт заказчысы | Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм элемтә министрлыгы |
| Ярдәмче программаның максаты | Татарстан Республикасы территориясендә элемтә һәм телекоммуникацияләрнең заманча инфраструктурасын формалаштыру |
| Ярдәмче программаның бурычлары | 1. Мәгълүмат-телекоммуникация инфраструктурасын һәм аның нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрне камилләштерү.<br>2. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә мәгълүмати-телекоммуникация инфраструктурасын кертү юлы белән идарә итүнең нәтиҗәлелеген арттыру |
| Ярдәмче программаны тормышка ашыру вакытлары һәм этаплары | 2014 – 2021 еллар |
| Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре | Алдан хисаплау буенча, Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән Ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 5 154 454,46 мең сум тәшкил итә, шул исәптән түбәндәге еллар буенча:<br>2014 ел – 685 173,90 мең сум;<br>2015 ел – 569 956,08 мең сум;<br>2016 ел – 616 400,75 мең сум;<br>2017 ел – 722 519,7 мең сум;<br>2018 ел – 818 650,43 мең сум;<br>2019 ел – 576 511,2 мең сум;<br>2020 ел – 576 511,2 мең сум; |

| | |
|---|---|
| | 2021 ел – 588 731,2 мең сум.<br>Ярдәмче программаны финанслау күләме фараз характерында була һәм чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетын формалаштырганда ел саен билгеләнгән тәртиптә тәгаенләнергә тиеш |
| Еллар буенча бүлеп, Ярдәмче программаны тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм Ярдәмче программаның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | Ярдәмче программаны тормышка ашыру барышында 2021 ел ахырына түбәндәге күрсәткечләргә ирешү планлаштырыла:<br>мобиль элемтә операторлары өчен инфраструктур мәйданчыклар саны – 200 берәмлек;<br>Татарстан Республикасының дәүләт интеграцияләнгән телекоммуникация системасы ресурсларыннан файдалану хокукына ия булган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнары өчен «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәренә оештырылган тоташтырулар өлеше – 100 процент.<br>Еллар буенча бүлеп, Ярдәмче программаны тормышка ашыруны бәяләү күрсәткечләре (индикаторлары) 5 нче таблицада китерелә»; |

II бүлектә:

бишенче абзацта «2014 – 2020» саннарын «2014 – 2021» саннарына алмаштырырга;

5 нче таблицаны  түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5 нче таблица

Еллар буенча  Программа максатларына һәм бурычларына ирешү күрсәткечләре (индикаторлары)

| Максат | Бурыч | Индикатор | 2013 ел | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Татарстан Республикасы территориясендә элемтә һәм телекоммуникацияләрнең заманча инфраструктурасын формалаштыру | 1. Мәгълүмати-телекоммуникация инфраструктурасын һәм аның нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрне камилләштерү | мобиль элемтә операторлары өчен инфраструктур мәйданчыклар саны, берәмлек | 0 | 20 | 78 | 120 | 125 | 150 | 170 | 200 | 200 |
| | 2. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә мәгълүмати-телекоммуникация инфраструктурасын кертү юлы белән идарә итүнең нәтиҗәлелеген арттыру | Татарстан Республикасының дәүләт интеграцияләнгән телекоммуникация системасы ресурсларыннан файдалану хокукына ия булган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнары өчен «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәренә оештырылган тоташтырулар өлеше, % | 87,1 | 89,9 | 92,2 | 94,5 | 96,6 | 97,8 | 98,3 | 100 | 100»; |

III бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. Ярдәмче программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

Алдан хисаплау буенча, Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән Ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 5 154 454,46 мең сум тәшкил итә, шул исәптән түбәндәге еллар буенча:

2014 ел – 685 173,9 мең сум;
2015 ел – 569 956,08 мең сум;
2016 ел – 616 400,75 мең сум;
2017 ел – 722 519,7 мең сум;
2018 ел – 818 650,43 мең сум;
2019 ел – 576 511,2 мең сум;
2020 ел – 576 511,2 мең сум;
2021 ел – 588 731,2 мең сум.

Ярдәмче программаны финанслау күләме фараз характерында була һәм чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетын формалаштырганда ел саен билгеләнгән тәртиптә тәгаенләнергә тиеш.

Озак вакытлы чорга Ярдәмче программаны финанслау күләмнәрен хисаплап чыгару 2030 елга кадәрге чорга Россия Федерациясен социаль-икътисадый үстерү фаразының инфляция индекслары нигезендә гамәлгә ашырылды.»;

«2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының мәгълүмати киңлек инфраструктурасын үстерү һәм камилләштерү» ярдәмче программасында:

исемендә «2014 – 2020» саннарын «2014 – 2021» саннарына алмаштырырга;

Ярдәмче программа паспортын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ярдәмче программа паспорты

| | |
|---|---|
| Ярдәмче программаның исеме | «2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасының мәгълүмати киңлек инфраструктурасын үстерү һәм камилләштерү» (алга таба – Ярдәмче программа) |
| Ярдәмче программа дәүләт заказчысы | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы (алга таба – Агентлык) |
| Ярдәмче программаның максаты | Халыкка күрсәтелә торган мәгълүматның сыйфатын һәм оперативлыгын арттыру, Татарстан Республикасының ике дәүләт теле тигезлеген тәэмин итү |
| Ярдәмче программаның бурычы | Татарстан Республикасы мәгълүмат киңлеген һәм массакүләм коммуникацияләрне үстерү һәм дәүләт ярдәме күрсәтү |

| | |
|---|---|
| Ярдәмче программаны тормышка ашыру вакытлары һәм этаплары | 2014 – 2021 еллар |
| Ярдәмче программаны еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп финанслау күләмнәре | Алдан хисаплау буенча, Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән Ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 9 906 569,81 мең сум тәшкил итә, шул исәптән түбәндәге еллар буенча:<br>2014 ел – 1 197 028,0 мең сум;<br>2015 ел – 1 192 716,6 мең сум;<br>2016 ел – 1 219 441,13 мең сум;<br>2017 ел – 1 250 259,18 мең сум;<br>2018 ел – 1 558 911,9 мең сум;<br>2019 ел – 1 160 727,8 мең сум;<br>2020 ел – 1 162 320,1 мең сум;<br>2021 ел – 1 165 165,1 мең сум.<br>Ярдәмче программаны финанслау күләме фараз характерында була һәм чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетын формалаштырганда ел саен билгеләнгән тәртиптә тәгаенләнергә тиеш |
| Еллар буенча бүлеп, Ярдәмче программаны тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм Ярдәмче программаның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | Ярдәмче программаны тормышка ашыру барышында 2021 ел ахырына түбәндәге күрсәткечләргә ирешү планлаштырыла:<br>узган елның шул ук чорына карата челтәр басмаларыны карауны артуы – 10 процент;<br>дәүләт ярдәме хисабына эфирга чыгарылган телерадиотапшырулар күләме – 21 мең сәг.<br>Еллар буенча бүлеп, Ярдәмче программаны тормышка ашыруны бәяләү күрсәткечләре (индикаторлары) таблицада китерелә»; |

II бүлектә:

бишенче абзацта «2014 – 2020» саннарын «2014 – 2021» саннарына алмаштырырга;

таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Еллар буенча Программа максатларына һәм бурычларына ирешү күрсәткечләре (индикаторлары)

| Максат | Бурыч | Индикатор | 2013 ел | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Халыкка күрсәтелә торган мәгълүматның сыйфатын һәм оперативлыгын арттыру, Татарстан Республикасының ике дәүләт теле тигезлеген тәэмин итү | Татарстан Республикасы мәгълүмат киңлеген һәм массакүләм коммуникацияләрне үстерү һәм дәүләт ярдәме күрсәтү | узган елның шул ук чорына карата челтәр басмаларыны карауны артуы, % | 270 | 90 | 114 | 172 | 10 | 10 | 10 | 10 | 10 |
| | | дәүләт ярдәме хисабыннан эфирга чыгарылган телерадиотапшырулар күләме, сәгать | 13,3 | 22 | 21 | 21 | 21 | 21 | 21 | 21 | 21»; |

III бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. Ярдәмче программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

Алдан хисаплау буенча, Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән Ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 9 906 569,81 мең сум тәшкил итә, шул исәптән түбәндәге еллар буенча:
2014 ел – 1 197 028,0 мең сум;
2015 ел – 1 192 716,6 мең сум;
2016 ел – 1 219 441,13 мең сум;
2017 ел – 1 250 259,18 мең сум;
2018 ел – 1 558 911,9 мең сум;
2019 ел – 1 160 727,8 мең сум;
2020 ел – 1 162 320,1 мең сум;
2021 ел – 1 165 165,1 мең сум.
Ярдәмче программаны финанслау күләме фараз характерында була һәм тиешле финанс елына Татарстан Республикасы бюджетын формалаштырганда ел саен билгеләнгән тәртиптә тәгаенләнергә тиеш.
Озак вакытлы чорга Ярдәмче программаны финанслау күләмнәрен хисаплап чыгару 2030 елга кадәрге чорга Россия Федерациясен социаль-икътисадый үстерү фаразының инфляция индекслары нигезендә гамәлгә ашырылды.»;

«2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында мәгълүмати технологияләр өлкәсендәге икътисадый мохитне һәм кеше капиталын үстерүгә дәүләт ярдәме күрсәтү» ярдәмче программасында:
исемендә «2014 – 2020» саннарын «2014 – 2021» саннарына алмаштырырга;
Ярдәмче программа паспортын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ярдәмче программа паспорты

| | |
|---|---|
| Ярдәмче программаның исеме | «2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасында мәгълүмати технологияләр өлкәсендәге икътисадый мохитне һәм кеше капиталын үстерүгә дәүләт ярдәме күрсәтү» (алга таба – Ярдәмче программа) |
| Ярдәмче программа дәүләт заказчысы | Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм элемтә министрлыгы (алга таба – Министрлык) |
| Ярдәмче программаның максаты | Мәгълүматлаштыру һәм элемтә өлкәсендә дәүләт сәясәтен тормышка ашыру |
| Ярдәмче программаның бурычы | 1. Мәгълүмати мохитнең инвестицияләр җәлеп итүчәнлеген арттыру.<br>2. Министрлык һәм аның ведомство буйсынуындагы учреждениеләрнең нәтиҗәле эшчәнлеген тәэмин |

| | |
|---|---|
| | итү. |
| Ярдәмче программаны тормышка ашыру вакытлары һәм этаплары | 2014 – 2021 еллар |
| Ярдәмче программаны еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп финанслау күләмнәре | Алдан хисаплау буенча, Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән Ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 787 164,19 мең сум тәшкил итә, шул исәптән түбәндәге еллар буенча:<br>2014 ел – 127 994,23 мең сум;<br>2015 ел – 102 291,14 мең сум;<br>2016 ел – 109 167,47 мең сум;<br>2017 ел – 118 501,52 мең сум;<br>2018 ел – 104 875,5 мең сум;<br>2019 ел – 71 152,7 мең сум;<br>2020 ел – 72 541,1 мең сум;<br>2021 ел – 80 640,53 мең сум.<br>Ярдәмче программаны финанслау күләме фараз характерында була һәм чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетын формалаштырганда ел саен билгеләнгән тәртиптә төгәенләнергә тиеш |
| Еллар буенча бүлеп, Ярдәмче программаны тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм Ярдәмче программаның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | Ярдәмче программаны тормышка ашыру барышында 2021 ел ахырына түбәндәге күрсәткечләргә ирешү планлаштырыла:<br>бер ел эчендә гамәлгә ашыруга җиткерелгән мәгълүмати технологияләр өлкәсендә инкубацияләнгән проектлар өлеше – 40 процентов;<br>ведомство карамагындагы учреждениеләр тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтүдән керемнәр күләмнәренең план күрсәткечләрен үтәү – 100 процентов.<br>Еллар буенча бүлеп, Ярдәмче программаны тормышка ашыруны бәяләү күрсәткечләре (индикаторлары) 1 нче таблицада китерелә»; |

II бүлектә:

бишенче абзацта «2014 – 2020» саннарын «2014 – 2021» саннарына алмаштырырга;

таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Еллар буенча Программа максатларына һәм бурычларына ирешү күрсәткечләре (индикаторлары)

| Максат | Бурыч | Индикатор | 2013 ел | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Мәгълүматлаштыру һәм элемтә өлкәсендә дәүләт сәясәтен тормышка ашыру | 1. Мәгълүмати мохитнең инвестицияләр җәлеп итүчәнлеген арттыру | бер ел эчендә гамәлгә ашыруга җиткерелгән мәгълүмати технологияләр өлкәсендә инкубацияләнгән проектлар өлеше, % | 38 | 40 | 40 | 40 | 40 | 40 | 40 | 40 | 40 |
| | 2. Министрлык һәм аның ведомство буйсынуындагы учреждениеләрнең нәтиҗәле эшчәнлеген тәэмин итү. | ведомство карамагындагы учреждениеләр тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтүдән керемнәр күләмнәренең план күрсәткечләрен үтәү, % | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100»; |

III бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. Ярдәмче программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

Алдан хисаплау буенча, Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән Ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 787 164,19 мең сум тәшкил итә, шул исәптән түбәндәге еллар буенча:

2014 ел – 127 994,23 мең сум;
2015 ел – 102 291,14 мең сум;
2016 ел – 109 167,47 мең сум;
2017 ел – 118 501,52 мең сум;
2018 ел – 104 875,5 мең сум;
2019 ел – 71 152,7 мең сум;
2020 ел – 72 541,1 мең сум;
2021 ел – 80 640,53 мең сум.

Ярдәмче программаны финанслау күләме фараз характерында була һәм чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетын формалаштырганда ел саен билгеләнгән тәртиптә тәгаенләнергә тиеш.

Озак вакытлы чорга Ярдәмче программаны финанслау күләмнәрен хисаплап чыгару 2030 елга кадәрге чорга Россия Федерациясен социаль-икътисадый үстерү фаразының инфляция индекслары нигезендә гамәлгә ашырылды.»;

Программага кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәлә);
Программага 2 нче кушымта өстәргә (карарга теркәлә).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин